КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 28 апрель г.Казань № 542

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә һәм аның гаилә әгъзаларына, шул исәптән дәүләт граждан хезмәткәре пенсиягә чыкканнан соң медицина хезмәте күрсәтү тәртибе турында» 2006 ел, 10 июль, 352 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә һәм аның гаилә әгъзаларына, шул исәптән дәүләт граждан хезмәткәре пенсиягә чыкканнан соң медицина хезмәте күрсәтү тәртибе турында« 2006 ел, 10 июль, 352 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 23 декабрь, 1005 нче, 2016 ел, 21 июнь, 422 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментына» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә һәм аның гаилә әгъзаларына, шул исәптән дәүләт граждан хезмәткәре пенсиягә чыкканнан соң медицина хезмәте күрсәтү тәртибе турында нигезләмәдә:

1.1 пунктта «(2003 елның 24 сентябрендәге 43-ТРЗ номерлы, 2003 елның 16 декабрендәге 52-ТРЗ номерлы, 2004 елның 4 декабрендәге 60-ТРЗ номерлы, 2005 елның 25 октябрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары белән кертелгән үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне исәпкә алып)» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.6. Дәүләт хезмәткәренең гаилә әгъзалары дигәндә ире (хатыны), кечкенәдән инвалид балалар арасыннан 18 яшьтән өлкәнрәк балалары, һөнәри белем бирү оешмаларында һәм көндезге уку формасы буенча югары белем бирү мәгариф оешмаларында белем алучы 18 яшьтән 23 яшькә кадәрге балалары, бергәләп (фактта) яисә теркәү урыны буенча яшәүче ата-аналар аңлашыла.»;

2.1 пунктта «йә аның хезмәт кенәгәсе (Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан таныкланган күчермәсе) - пенсиягә чыккан очракта» сүзләрен «йә аның хезмәт кенәгәсе (Татарстан Республикасы Раисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан таныкланган күчермәсе) яисә законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр - пенсиягә чыккан очракта» сүзләренә алмаштырырга;

2.2 пунктта «Дәүләт хезмәткәрләренең кечкенәдән инвалид балаларына» сүзләрен «дәүләт хезмәткәрләренең 18 яшьтән өлкәнрәк яшьтәге кечкенәдән инвалид балалар арасыннан балаларына» сүзләренә алмаштырырга;

2.3 пунктта «3 яшьтән» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6. Дәүләт хезмәткәренең 17 яшькә кадәрге (17 яшьне кертеп) гаилә әгъзалары, шул исәптән дәүләт хезмәткәре пенсиягә чыкканнан соң, Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтү дәүләт гарантияләре программасы нигезендә гомуми нигезләрдә яшәү урыны һәм (яисә) мәҗбүри медицина иминияте полисын беркетү урыны буенча медицина оешмаларында беренчел медицина-санитария ярдәме алалар.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин